| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Кадряковского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Кадрәк авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.11.2018 Кадрәк авылы № 46-3

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында»гы карарына 2014 елның 10 ноябрендәге 31-1 номерлы үзгәрешләр кертү турында»

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадрәк авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында»гы 2014 елның 10 ноябрендәге 31-1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 пунктта:

а) 1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"гаражлар һәм машина кую урыннары, шул исәптән салым салу объектларында урнашкан әлеге карарның 4.1 пунктында күрсәтелгән;»

б) 2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"фатирлар, фатир өлешләре;»

в) 3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«торак йортлар, торак йортларның өлешләре;»

г) 3 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«составына бер генә булса да торак йорт керә торган, бердәм күчемсез комплекс;»

1.2. 3 Пункт:

а) 3.1 пунктын өстәргә.

«3.1. Физик затлар милкенә салым түләүдән азат итәргә:

3.1.1. 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнарны;

3.1.2. пунктындагы 3.1.1. пунктында күрсәтелгән гражданнарның балаларын.»

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадрәк авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 июлендә кабул ителгән 41-2 номерлы «Физик затларның милкенә салым турында»гы карар үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән бер ай узгач һәм чираттагы салым чорының 1 нче числосыннан да иртәрәк булмаган вакыт узгач үз көченә керә

һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен бирә.

4. Әлеге карарны Кадрәк  авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына куярга, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтына agryz.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталына pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Әлеге Карарны үтәүгә контрольне үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
авыл җирлеге Башлыгы А.А. Михайлов